РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Асеевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района
ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево, Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башлыгы
Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» ноябрь 2021 ел. № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 30 ноябрендә сәгать 14.00да үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җиенының беренче этабын билгеләргә: Үзәк урам, 1нче йорттан 100нче йортка кадәр, Мәктәп урамы, 1нче йорттан 7нче йортка кадәр.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 30 ноябрендә сәгать 15.00да үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җиенының беренче этабын билгеләргә: Елга Аръягы урамы, 1нче йорттан 40нчы йортка кадәр, Тау Асты урамы, 1нче йорттан 5нче йортка кадәр, Наратлы урамы, 1нче йорттан 19нчы йортка кадәр, Ясле урамы, 1нче йорттан 7нче йортка кадәр.
3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты – 30 ноябрь 2021ел 14.00 сәг.тән 15.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты – 30 ноябрь 2021 ел 15.00 сәг.тән 16.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын үткәрү урыны –Әсәй авылы, Үзәк ур., 38Г йорты, Әсәй авыл мәдәният йорты залы ;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Әсәй авылы, Үзәк урамы, 38Б йорты;

- сайлау хокукына ия булган Әсәй торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Әсәй торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022елда Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әсәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Әсәй авылында җәйге чорда территорияне чабу (инструмент сатып алу, ГСМ, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Әсәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әсәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Әсәй авылы урамнарына вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, билгеләр кую, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсәй авылында янгын сүндерү депосын тоту (электр энергиясе һәм җылылык өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. Һәм Үзәк ур., 38Б йорт, Үзәк ур., 60йорт, Елга Аръягы ур., 27йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан

Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: З.Ә. Идрисов.